**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Чубар-Абдулловского сельского поселения Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы БАШЛЫГЫ**

ул. Советская, д. 81 , село Чубар-Абдуллово
Азнакаевского муниципального района, 423323
Тел. (факс) (85592)38-7-30
Chabd.Azn@tatar.ru

Совет урамы, 81, Чубар-Абдул авылы
Азнакай муниципаль районы, 4233237
Тел. (факс) (85592) 38-7-30
Chab.Azn@tatar.ru


## ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　КАРАР

«16» март 2021л　　　　№ 1

«Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлеге Советының 2020 елга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Чубар Абдулл авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл Советының 2012 елның 19 апрелендәге 50 номерлы карары белән кабул ителгән авыл җирлеге халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, халык алдында тыңлаулар үткәрү юлы белән Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын гамәлгә ашыру максатыннан Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлеге Советының «2019 елда Азнакай муниципаль районы Карамалы авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында» гы карары проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен халык алдында тыңлаулар үткәрү максатыннын карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлеге Советының "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлегенең 2020 елгы бюджеты үтәлеше турында"гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

2. Халык алдында ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы - Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлеге башлыгы.

3. Билгеләргә:

- үткәрү вакыты-2021 елның 08 апреле 10.00 сәгатьтә;

- үткәрү урыны-Чубар Абдулл авылы мәдәният йорты:

- тикшерелә торган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тәкъдим ителә торган адрес: 423323 ТР, Азнакай районы, Чубар Абдулл авылы, Совет урамы, 81 нче йорт.

4. Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлеге башкарма комитетына:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлеге Советының "2020 елда Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проекты буенча, гамәлдәге законнар, Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлегенең норматив-хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карарда билгеләнгән срокта ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлеге Советының "2020 елда Азнакай муниципаль районы Чубар Абдулл авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында" гы карары проектын (1 нче кушымта) Азнакай муниципаль районы Чубар Абудлл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http//aznakayevo.tatarstan.ru) веб-адресы буенча 2021 елның 17 мартыннын да сонга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карарны Чубар Абдулл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес: http://pravo.tatarstan.ru ,Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http//aznakayevo.tatar.ru//. 2021 елның 17 мартыннан да соңга калмыйча игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык Н.А.Фәтхетдинов